Басыйр РАФИКОВ



# УЙЛАНЫР ВАКЫТ

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

Рафиков Басыйр

# Уйланыр вакыт = Время задуматься

«Татарское книжное издательство»

**Басыйр Р.**

Уйланыр вакыт = Время задуматься / Р. Басыйр — «Татарское книжное издательство»,

ISBN 978-529-803525-5

Әлеге китапка Басыйр Рафиковның соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләре туплап бирелде.

ISBN 978-529-803525-5

© Басыйр Р.
© Татарское книжное издательство

# Содержание


Туган җирем 6
«Кечкенә ватаным, гаеп итмә…» 7
«Уртак бәхет нәрсә?..» 8
«Җирнең йөзен…» 9
Уйлар 10
Ил белән 11
Җыр өзелми 12
«Уналтынчы гасырдан катлы…» 13
«Озын юллар үтәм…» 14
«Меңьеллык бөек шәһәрем…» 15
«Хәтер сызлавыннан…» 16
«Бу ярым ай…» 17
«Без киләбез юлдан икәү…» 18
Борынгы каберләр 19
«Ашкына зат кара төннән…» 20
«Агачлар шәрә…» 21
«Тал-тирәкләр йокымсырый…» 22
Өчкүл авылы 23
Учак янында 24
Атларга хыянәт 25
Ноктюрн 26
Бер чиләк су 27
Картлыкта 28
Конец ознакомительного фрагмента. 29

# Басыйр Рафиков
# Уйланыр вакыт. Шигырьләр



# Туган җирем

Ил, шәһәрләр сансыз күп булса да,
Туган илем җирдә бер генә.
Әти, бабамнарның тир, каннары
Әйләнгәннәр тарту көченә.

Урманнары, кырда игеннәре,
Кабатланмас якын авыллар,
Зираттагы гыйффәтле каеннар
Күңелемне әсир алганнар.

Туган җирләр, изге туган җирләр,
Сез күңелдә, җирдә бер генә.
Минем кебек, башын түбән иеп,
Сәҗдә кылмый сезгә кем генә?!

# «Кечкенә ватаным, гаеп итмә…»

*Малая Родина, не обессудь.*
***С. Куняев***

Кечкенә ватаным, гаеп итмә,
Мин бит ташлап китмәдем сине.
Котсыз килгән утызынчы еллар
Синнән куып җибәрде мине.
Сансыз еллар үтә, онытмыйсың
Кендек каның тамган җирне.
Синең белән, изге халкың белән
Әнкәм рухы бәйли мине.

# «Уртак бәхет нәрсә?..»

Уртак бәхет нәрсә? –
Милләтемнең берлеге.
Уртак шатлык нәрсә? –
Халкымның терелеге.
Уртак бәхет нәрсә? –
Татарның мәңгелеге.

# «Җирнең йөзен…»

Җирнең йөзен
Канга манып
Шәфәкъ бата.
Бер-бер артлы,
Кабаланып,
Йолдыз калка.
Төн дә үтәр,
Юлга дәшеп
Кояш чыгар.
Әзерме сез,
Киләчәккә
Атлаучылар –
Халык бәхтен,
Азатлыгын
Яклаучылар?

# Уйлар

Идел буйлап, уйлар уйлап,
Үткәнгә таба барам.
Дулкыннар серен аңламый,
Берсүзсез телдән калам.

Мондадыр күк яшерелгән
Тарих маҗаралары.
Үзе ерак, җанга якын
Аклары, каралары.

Мондадыр күк бабамнарның
Дөнья көткән чаклары,
Әле сүнеп өлгермәгән
Дөрләгән учаклары.

Алга таба әйди шунда
Идел суы агышы.
Ишетелгән кебек кинәт
Горур варис тавышы.

Яратам мин күзәтергә
Елгаларның агышын.
Алар тизләтәләр кебек
Халкым алга барышын.

# Ил белән

Үткәннәр җиңел булмады,
Бүген дә җиңел түгел.
Илең белән яшәгәндә,
Барсын кичерә күңел.

Ил сугышта – син сугышта,
Тынычлыкта – син тыныч.
Ул сиңа таянмый калса,
Чолгап ала куркыныч.

# Җыр өзелми

Халык зур!
Үлемсез,
Көрәштә юл таба,
Өзелгән җырларның өстендә елама!

Тарихта бер мизгел гасырлар дигәнең,
Буыннар күтәрә мәңгелек җилкәнен.

Орлыктан наратлар шыталар ташта да,
Яралгы ашкына тормышын башларга.

Күчәрдә Җир шары туктаусыз әйләнә,
Өзелгән җырларга яңасы бәйләнә.

Халык зур!
Үлемсез,
Көрәштә юл таба,
Өзелгән җырларның өстендә елама!

# «Уналтынчы гасырдан катлы…»

Уналтынчы гасырдан катлы
Йортлар калмаганнар Казанда.
Экскурсантлар күрә алмас
Мәчет, мәдрәсәләрне анда.

Бүгенге көннәрдә төзелгән
Мәһабәт Кол Шәриф мәчете,
Киләчәккә түгел, үткәнгә
Йөзен борып тора шикелле.

Калган бар изге йортлар йөзе
Юнәлгән киләчәккә таба.
Аларның барлык теләкләре –
Халыкны әйдәп бару алга!

# «Озын юллар үтәм…»

Озын юллар үтәм,
Өметләрне сүтәм.
Көн дә үзем һаман
Үзгәрешләр көтәм.

Булыр алар шиксез,
Тотылыр ул ялган.
Якты көнгә Илаһ
Изге юллар салган.

# «Меңьеллык бөек шәһәрем…»

Меңьеллык бөек шәһәрем,
Уеласың күңелгә.
Меңьеллык һәйкәлләр күрәм,
Сокланам бүгенеңә.

Сөембикә манарасы
Җәлилгә якын икән.
Аларның тарих юлында
Бердәмлекләрен сизәм.

Казан бөеклеген күреп
Шатмын горурлыгына.
Ышанам бу гүзәллекнең
Мәңге торырлыгына.

# «Хәтер сызлавыннан…»

Хәтер сызлавыннан
Арына алмыйм.
Үткәннәрне барлыйм,
Халкыма карыйм.
Дәүләтсез калганбыз
Дуслык юклыктан,
Мәхрүм ителгәнбез
Ирек, хокуктан.

# «Бу ярым ай…»

Бу ярым ай
Манарада.
Батмыйдыр ул
Ал таңнарда.

Бу ярым ай
Күрсәтә юл
Изге якка
Барганнарга.

# «Без киләбез юлдан икәү…»

Без киләбез юлдан икәү:
Һавада – ай, җирдә – мин.
Онытканмын икән әле:
Өченчебез мыжык җил.
Һәрберебезнең үз эше бар:
Айның – төнне күзәтү;
Җилнең – һава сафландыру,
Дөнья йөзен җилләтү.
Миндә нинди йөкләмә соң?
Йөрмимен аны эзләп.
Һәр ватанпәрвәрнең эше –
Илгә, халыкка хезмәт.

# Борынгы каберләр

Үткәннәр тузгып яткан көл түгел,
Үткәннәр – тешләк, үҗәт хәтер.
Вакыт җиткәч бәреп чыгу өчен,
Аларга киртә түгел кабер.

Теләптерме, юкмы, иске тарих
Борынгы хәлләрне бутаган.
Чуалганны вөҗдансыз мәхлуклар
Үз файдасына кулланган.

Яшерелгән хаклыкны табарга
Сезнең янга бүген килдек без.
Рәхмәт сезгә, борынгы каберләр,
Хакыйкатьне ачып бирдегез.

# «Ашкына зат кара төннән…»

Ашкына зат кара төннән
Якты көннәргә таба.
Иркәләп каршылый аны
Таң җиле – иркә саба.

Нурлы кояш яктысында
Җиһан җанланып китә.
Сөйгән халкы арасында
Эш көтә, тормыш көтә.

Барсы була көн йөзендә –
Мәхәббәт, чәчәк исе.
Тормышында хозурланып,
Шатланып яши кеше.

# «Агачлар шәрә…»

Агачлар шәрә.
Биткә кар бәрә.
Дуслар кабердә.

Бергә укулар,
Канлы сугышлар –
Бар да хәтердә.

Күргән афәтләр,
Мизгел бәхетләр
Күңел түрендә.

Илаһи биргән
Канат астында
Тормыш бүген дә.

# «Тал-тирәкләр йокымсырый…»

Тал-тирәкләр йокымсырый,
Таң ата гына әле.
Бу, күрәсең, табигатьнең
Тынлыкка талган мәле.

Нидер көткән сыман тынлык,
Баса яныңа килеп.
Ә нигәдер күңлең, җаның
Булышмый җавап биреп.

Үз уе, хыялларына
Китә ул тирән кереп.
Чияләнә хәл-әхвәлләр,
Бутала бүген, элек.

Тормыш артыннан калмыйм дип
Йөргәнмен киртә куеп.
Кирәкләре булмаган бит,
Өлгерсәм иде җыеп.

Яшьләр башлыйлар тормышны,
Ашыкмый баштан алып.
Мин ашыгып дәвам итәм,
Яшьтәшләрдән дә калып.

# Өчкүл авылы

Бөек Ватан сугышына тикле
Хәтерлим мин Өчкүл авылын.
Бүленгәндә, Чиләбедән чыгып,
Курган өлкәсендә калуын.

Каен урманында каен йортлар,
Урманында җиләк – нигъмәтләр.
Кесәдә дә, өстәлдә курмач,
Тәмле икән бодай куыргач.

Тегермән дә, клуб та юк монда,
Мәктәпләре бары башлангыч.
Ваемсыз күк авыл кешеләре,
Чит кешегә күренеш башваткыч.

Бүген телевизор экранында
Өчкүл. Анда таш мәчет салынган.
Ташкын кебек булып киткән халык,
Яше, карты шунда агылган.

Нинди шатлык, нинди ямьле күренеш –
Авыл уяу, авыл мәчетле.
Эзәрлекләү, колхоздан котылгач,
Халык көтә изге бәхетне.

# Учак янында

Кара төнгә очкан ялкын
Күңелне борчый һаман,
Ырудан ыруга күчкән
Ул учактан һәр заман.

Ул яктырткан бабамнарның
Төн уртасы юлларын.
Бүген аның ялкынында
Чәбәләнә уйларым.

Теләгем – халкым, ыруым
Мәңге сакласын аны.
Учак янып сүрелгәнче
Атсын кодрәтле таңы.

# Атларга хыянәт

Далага чыксам –
Бабамнар иле.
Күз ачып йомсам –
Атлар өере.

Кабат күз ачып
Йомсам – машина.
Ул мәлгунь җиткән
Атлар башына.

Заман шайтаны
Кайда карама,
Тузан туздыра,
Газы тарала.

Борын-борынгы
Дуслыклар тар-мар.
Атка хыянәт
Иткән ир-атлар.

Бүгенге тормыш
Кичерми моны.
Атка атлана
Заманның улы.

# Ноктюрн

Көмеш дулкыннар
Ярларны ялый.
Чыланган таллар
Чәчләрен тарый.

Көяз күренмәк
Кояшка алар.
Төн кыяфәтен
Алыштыралар.

Алтын кояштан
Гәрәбә нурлар
Юлларын туры
Шунда боралар.

Үзләре баккан,
Нурларын аткан
Яшел җиһанга
Гашыйклар алар.

# Бер чиләк су

*В. Мироновтан*

Чиләк белән чумырып алып,
Елга суын ташыйлар өйгә.
Ник дулкын өстендә шөлдиләр
Зар елыйлар, су, шуны сөйлә.

Сөйлә, ничек ташлар өстендә
Хатын-кызлар бәләк уйната.
Ат ирене ничек елгада
Үз шәүләсен үбеп чылата?

Күпме болыт, күпме йолдызны
Тирбәттең син дулкын өстендә?
Искә төшер томан киндерен,
Күпме эңгер ятты өстеңдә.

Тынгысыз су, сөйлә, кемнәрнең
Борчуларын төяп эченә,
Поездлар шаулаша күпердә,
Кайтавазлар чәчеп өстеңә?

Буйсынмастай күпме бозларны
Ваткансыңдыр аккан чорыңда…
Чиләк эчендәге салкын су,
Сөйлә әле шулар турында?

# Картлыкта

Адым саен
Туктап кала
Юлда кортка.

Гашыйк булып
Карап тора
Һәрбер йортка.

Яшь чакларын,
Дус-ишләрен

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.